**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в состав Комитета по присуждению премии Президента Республики Татарстан за вклад в развитие институтов гражданского общества в Республике Татарстан

В целях совершенствования деятельности Комитета по присуждению премии Президента Республики Татарстан за вклад в развитие институтов гражданского общества в Республике Татарстан **постановляю**:

1. Внести в состав Комитета по присуждению премии Президента Республики Татарстан за вклад в развитие институтов гражданского общества в Республике Татарстан (далее – Комитет), утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 3 июля 2015 года № УП-619 «Об учреждении премии Президента Республики Татарстан за вклад в развитие институтов гражданского общества в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 4 июня 2016 года № УП-503, от 3 июня 2017 года № УП-460 и от 27 января 2018 года № УП-109), следующие изменения:

а) ввести в состав Комитета:

Сабурскую Сарию Харисовну – Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан (по согласованию);

Сафину Зульфию Нурмухаметовну – руководителя государственного казенного учреждения «Аппарат Общественной палаты Республики Татарстан», утвердив ее секретарем Комитета;

б) изложить в следующей редакции наименования должностей членов Комитета:

В.В. Вавилова – «председатель Правления Регионального общественного благотворительного фонда помощи детям, больным лейкемией, Республики Татарстан имени Анжелы Вавиловой (по согласованию)»;

Р.Р. Зарипова – «председатель Комиссии Общественной палаты Республики Татарстан по молодежной политике и патриотическому воспитанию (по согласованию)»;

О.А. Калашниковой – «председатель Татарстанской республиканской организации Общероссийского профессионального союза работников государственных учреждений и общественного обслуживания Российской Федерации (по согласованию)»;

А.В. Королева – «председатель Комиссии Общественной палаты Республики Татарстан по правовым вопросам, общественному контролю, общественной экспертизе (по согласованию)».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
17 ноября 2018 года
№ УП-778

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты составына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы һәм 2018 елның 27 гыйнварындагы ПУ-109 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составына кертергә:

Сабурская Сәрия Харис кызын – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне (килешү буенча);

Сафина Зөлфия Нурмөхәммәт кызын – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесен, аны Комитет секретаре итеп расларга;

б) Комитет әгъзалары вазыйфаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

В.В. Вавиловның – «Татарстан Республикасының лейкемия белән авыручы балаларга ярдәм итү буенча Анжела Вавилова исемендәге төбәк иҗтимагый хәйриячелек фонды идарәсе рәисе (килешү буенча)»;

Р.Р. Зариповның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының яшьләр сәясәте һәм патриотик тәрбия бирү буенча комиссиясе рәисе (килешү буенча)»;

О.А. Калашникованың – «Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать хезмәт күрсәтүе хезмәткәрләре гомумроссия һөнәр берлегенең Татарстан Республикасы оешмасы рәисе (килешү буенча)»;

А.В. Королевның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының хокук мәсьәләләре, иҗтимагый контроль, иҗтимагый экспертиза буенча комиссиясе рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 17 ноябрь
№ ПУ-778